ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге составына керүче Әтнә торак пункты

17 ноябрь 2023 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Әтнә торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. «2024 елда гражданнарның үзара салымын Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Әтнә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр кешедән 850 (Сигез йөз илле) сум күләмендә кертергә. (I төркем инвалидлар өчен; үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмый торган гражданнар; балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналар (законлы вәкилләр); Россия Армиясе сафларында вакытлы һәм контракт хезмәте үтүче хәрби хезмәткә чакырылучыларга, мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына 90% күләмендә ташлама каралган).

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Әтнә авылы зират коймасын төзекләндерү өчен материаллар алу;
- Әтнә авылы зиратының коймасын төзекләндерү;
- Янгынга каршы җиһазлар алу (янгынга каршы колонкаларга комплект детальләре);
- Әтнә авылының артезиан скважинасы өчен бер су кудыру насосы алу.»

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Балтач муниципаль районы сайтында baltasi.tatarstsn.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче:
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Заляев